**СОВЕТ ГОРОДА МАМАДЫШ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**ул. М. Джалиля, 23/33, г. Мамадыш, 422190**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАМАДЫШ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**
**М.Җәлил ур., 23/33, Мамадыш ш., 422190**

**тел.:(85563) 3-15-90, факс 3-24-00 ; e-mail:gorsovet.mamadysh@tatar.ru**

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 1-20** **от « 02 » октября 2017 г.**

Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре территориясендә җирле референдум билгеләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 23 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 11статьясы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесенең «Референдум үткәрү инициативасы турында» 2017 елның 20 сентябрендәге № 62 карары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Советының «Референдум үткәрү инициативасы турында» 20.09.2017 елның 20 сентябрендәге № 2-19 карары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Советының 2014 елның 18 октябрендәге № 1-26 карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм алардан файдалану тәртибе турында нигезләмә (Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Советының 20.09.2017 ел, № 1-19 карары редакциясендә), нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре территориясендә җирле референдумны 2017 елның 19 ноябренә билгеләргә.

2.Җирле референдумга чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында катнашканнарның тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәреннән кала, 300 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

2.. 1.Терроризм һәм экстремизмны профилактикалауда катнашу:
Мамадыш шәһәре территориясендә видеокүзәтү җайланмасы урнаштыру;

2.Торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктыртуны, урам исемнәре һәм йорт номерлары белән күрсәткечләр урнаштыруны кертеп):
Мамадыш шәһәре территориясендә электр белән тәэмин итү линияләрен капиталь ремонтлау, реконструкцияләү һәм төзү;
Мамадыш шәһәре территориясендә ике телдә урам исемнәре һәм йорт номерлары белән күрсәткечләр ясау һәм урнаштыру;
Мамадыш шәһәре территориясендә балалар уен мәйданчыкларын төзү һәм реконструкцияләү;

3. Каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым җыю) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу:
Мамадыш шәһәре территориясендә каты көнкүреш калдыкларын җыю урыннарын төзекләндерү;

4. Торак пунктта яшәүчеләрнең күпләп ял итү өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, шул исәптән гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буйларына ирекле керүен тәэмин итү:
Мамадыш шәһәре территориясендә пляжны төзекләндерү.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3.Әлеге карар Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында веб- http://mamadysh.tatarstan.ru веб- адресы буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге караның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Мамадыш муниципаль районы
Мамадыш шәһәре Башлыгы,
Мамадыш шәһәре Советы рәисе А.П.Иванов